| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| --- | --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Күгәй авылы

**2023 елның 16 гыйнваре** **№ 101**

2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, « Күгәй авыл җирлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Советыкарар итте:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәвен билгеләргә
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Күгәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Күгәй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Ф. Х. Хисаметдинова**